ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 776 14 декабрь 2017 ел

# Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга(кушымта).

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 декабрендәге 776 номерлы карары белән расланган кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1. 1.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү алучылар: яшәү урыны буенча Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләрендә яшәүче физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр)».

2. 1.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә».

3. 1.3. пунктындагы 1.3.1. пунктчасының икенче абзацында «Төзүчеләр проспекты, 12 нче йорт, 121 нче кабинет» сүзләрен «Мәктәп бульвары, 2а йорты» сүзләренә алыштырырга.

4. 1.3.1. пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты: 12 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр.»

5. 1.3. пунктындагы 1.3.1. пунктчасының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек урыннарына керү ирекле».

6. 1.3. пунктының 1.3.2. пунктчасындагы «e-nkana.ru» сүзен «e-nkama.ru» сүзе белән алыштырырга.

7. 1.4. пунктының сигезенче абзацындагы «Түбән Кама шәһәр Советының 2009 елның 26 ноябрендәге 27 номерлы карары белән кабул ителгән» сүзләрен «Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән кабул ителгән» сүзләренә алыштырырга.

8. 1.4. пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Түбән Кама шәһәр Советының 2015 елның 18 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе нигезләмәсе» нигезендә (алга таба – БК турында Нигезләмә);».

9. 1.4 пунктның унынчы абзацында «Башкарма комитет Җитәкчесенең 2006 елның 17 октябрендәге 8-р күрсәтмәсе белән расланган» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. 1.5. пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза астында (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату анлашыла

(2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла.

11. «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт» баганасындагы 2.1. пунктында «ТР Министрлар Кабинетының 190 нчы номерлы карарының 1 нче пункты» сүзләрен «Кагыйдәләр һәм тәртипнең 1 пункты» сүзләре белән алмаштырырга.

12. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.4. пунктының беренче, икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую яки учетка куюдан баш тарту турында карар кабул итү гариза биргән көннән алып бер ай эчендә башкарыла.

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешма реестрына кертү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү кертү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә башкарыла».

13. «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт» баганасындагы 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кагыйдәләр һәм тәртипнең 7, 17 пунктлары».

14. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

2) анкета (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

3) исемлек буенча нигезләү документлары (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

Гариза һәм документлар кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелергә мөмкин.».

15. «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт» баганасының 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кагыйдәләр һәм тәртипнең 7 пункты».

16. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) Күчемсез милеккә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан аның булучы (булган) күчемсез милек объектларына (гаиләнең һәр әгъзасына) аерым затның хокуклары турында өземтә.».

17. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган».

18. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.

Баш тарту өчен нигезләр:

1) Әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую хокукын расламаган документларны тапшыру;

2) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә гаризага теркәлә торган кирәкле документлар булмау һәм аларны тулысынча тутырмау;

3) гаризада һәм тапшырылган документларда күрсәтелгәннәргә туры килми торган мәгълүматларны ачыклау;

4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан торак шартларын начарайтуга китергән гамәлләр кылынган көннән тулы булмаган (биш ел) срок үтүе;

5) элек мөрәҗәгать итүчегә социаль ипотека системасында дәүләт ярдәме кысаларында, Кагыйдәләр һәм тәртип белән каралган очраклардан тыш, торак урыны бирү;

6) гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программаларында мөрәҗәгать итүченең катнашуы».

19. «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт» баганасының 2.9. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кагыйдәләр һәм тәртипнең 10 пункты».

20. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.13. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гариза кабул ителгән көнне башкарыла».

21.«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата муниципаль хезмәт күрсәтелә торган урыннарга таләпләр».

22. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү урынына инвалидларга тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

23. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәткечләре булып:

бинаның җәмәгать транспорты өчен уңайлы зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган биналар булу;

мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль хезмәт күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидлар өчен үтемлелекнең законнарда каралган шартлары булу тора.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:

гариза бирүчеләргә документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәте турында шикаятьләр булмау белән характерлана.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә хезмәттәшлеге күздә тотыла. Аралашу озынлыгы регламент белән билгеләнә.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт күрсәткәндә (алга таба – КФҮ) консультация, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.».

24. 3.1. пунктындагы 3.1.1. пунктчасының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую өчен мөрәҗәгать итүчеләрнең гаризаларын карау;».

25. 3.1. пунктындагы 3.1.2. пунктчасында «9 нчы кушымтада» сүзләрен «6 нчы кушымтада» сүзләре белән алмаштырырга.

26. 3.3. пунктындагы 3.3.2. пунктчасының дүртенче, бишенче, тугызынчы абзацларын төшереп калдырырга.

27. 3.3. пунктындагы 3.3.2. пунктчасының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гариза бирүчегә аларның исемлеген һәм алыну датасын күрсәтеп, документлар алуда расписка тапшыру.».

28. 3.3. пунктындагы 3.3.2. пунктчасының унберенче абзацында «яки гариза бирүчегә кайтарылган документлар» сүзләрен төшереп калдырырга.

29. 3.4. пунктындагы 3.4.1 пунктчасының өченче абзацын төшереп калдырырга.

30. Дүртенче абзацтагы «10 эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

31. 3.5. пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую өчен мөрәҗәгать итүчеләрнең гаризаларын карау».

32. 3.5. пунктындагы 3.5.1. пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату нигезендә Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

гаризага беркетелгән анкеталар һәм барлык кирәкле документларның булуын тикшерүне;

тиешле органнар белән мәгълүматны аныклау максатыннан, документларда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерүне;

иҗтимагый торак комиссиясе тарафыннан мөрәҗәгать итүчене исәпкә кую турындагы мәсьәләне карау өчен гаиләнең исәп эшен формалаштыруны гамәлгә ашыра.».

33. 3.5. пунктындагы 3.5.1. пунктчасының өченче абзацында «формалашкан» сүзен «формалаштырылган» сүзенә алыштырырга.

34. 3.5. пунктындагы 3.5.4. пунктчасының икенче абзацындагы «имзага тапшырылган бәяләмә» сүзләрен «имзага тапшырылган беркетмә» сүзләренә алмаштырырга.

35. 3.6 пунктындагы 3.6.1. пунктчасының бишенче абзацындагы «биш» сүзен «өч» сүзенә алыштырырга.

36. 3.6 пунктындагы 3.6.1. пунктчасының икенче-дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) мөрәҗәгать итүченең гаиләсе турында мәгълүматны социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куелган локаль исемлекләргә кертә;

2) мөрәҗәгать итүчегә уникаль хисап коды (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) биреп, социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую турында күрсәтмә проектын әзерли.

Комиссия исәпкә куюдан баш тарту турында карар кабул иткән очракта, Бүлек белгече исәпкә куюдан баш тарту турында күрсәтмә проектын әзерли (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) һәм килештерүгә җибәрә.».

37. 3.6. пунктындагы 3.6.1. пунктчасының алтынчы абзацында «(хатлар)» сүзен төшереп калдырырга.

38. 3.6. пунктындагы 3.6.2. пунктчасының беренче, өченче абзацларындагы «(хатлар)» сүзен төшереп калдырырга.

39. 3.6. пунктындагы 3.6.2. пунктчасының беренче абзацындагы «муниципаль район башлыгына» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга.

40. 3.6. пунктындагы 3.6.2. пунктчасының өченче абзацындагы «район башлыгына» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга.

41. 3.6. пунктындагы 3.6.3 пунктчасының беренче абзацындагы «район башлыгы» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга, «(хатлар)» сүзен төшереп калдырырга.

42. 3.6. пунктындагы 3.6.3. пунктчасының өченче абзацында «(хат)» сүзен төшереп калдырырга.

43. 3.6. пунктындагы 3.6.4. пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Исәпкә кую кире кагылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә куюдан баш тарту һәм баш тарту нигезләре турында хәбәр итә торган хат җибәрелә.».

44. 3.6. пунктындагы 3.6.6. пунктчасының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тәкъдим ителгән гаиләләр исемлеген, сәбәпләрен күрсәтеп, Башкарма комитетка кире кайтару.».

45. 3.6. пунктындагы 3.6.6. пунктчасының бишенче абзацында «Дәүләт торак фондының эш регламенты белән билгеләнгән срокта» сүзләрен «Кагыйдәләр һәм тәртип белән билгеләнгән срокта» сүзләре белән алыштырырга.

46. 3.6. пунктындагы 3.6.6. пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең гаиләсен Дәүләт торак фонды реестрына кертү яисә кертүдән баш тарту турында карар кабул итү.».

47. 3.7. пунктындагы 3.7.1. пунктчасының беренче абзацында «яки исәпкә куюдан баш тарту турында» сүзләрен «яки Дәүләт торак фонды реестрына кертүдән баш тарту турында» сүзләренә алмаштырырга.

48. 3.7. пунктындагы 3.7.1. пунктчасының өченче абзацында «яки исәпкә куюдан баш тарту турында» сүзләрен «һәм ДТФ реестрына кертү яки ДТФ реестрына кертүдән баш тарту турында» сүзләренә алыштырырга.

49. 3 бүлекне 3.8 пункты белән түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«3.8. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.8.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән составы, тапшырыла торган документлар формасы һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документ составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.8.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза бирә һәм документларны КФҮгә әлеге регламентның 2.5. пункты нигезендә тапшыра.

3.8.3. Гаризалар кабул итүче КФҮ белгече, КФҮ административ регламенты нигезендә:

документлар кабул итү белән бәйле процедураларны;

кергән гариза һәм документларны теркәүне;

документлар пакетын Бүлеккә җибәрүне гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.8.4. Бүлек белгече, КФҮдән документлар алгач, әлеге Регламентның 3.3.-3.6. пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.3.-3.6. пунктлары белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламент тарафыннан билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: КФҮгә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.8.5. КФҮ белгече кергән муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен теркәп, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.8.6. КФҮ белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен имза куйдырып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.».

50. 4.2. пунктында «муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, шулай ук инфраструктура үсеше бүлеге белгечләре тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесе яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

51. 5.1. пунктында «яисә муниципаль берәмлек Советына» сүзләрен төшереп калдырырга.

52. Административ регламентка 1-3 номерлы кушымталарны яңа теркәлә торган редакциядә бәян итәргә.

53. 4-6 номерлы кушымталарны, административ регламентка белешмә кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга.

54. Административ регламентта 7-9 номерлы кушымталарны 4-6 номерлы кушымталар дип санарга.

55. административ регламентка 6 нчы кушымтаны (блок-схема) теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә.

1 нче кушымта

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетына
(район, шәһәр исеме)
гр. ____________________________________________
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
________________________________________________
(адрес буенча шәһәрдә, поселокта, авылда яшәүче:
________________________________________________
почта индексы, тулы адрес, контакт телефоны)
________________________________________________
(адресы буенча теркәлгән: почта индексы, тулы адрес)
________________________________________________
________________________________________________
(число, ай, ел)

ГАРИЗА

________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булу сәбәпләрен күрсәтергә)
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
(гаиләнең бер әгъзасына торак мәйданы белән тәэмин ителү
________________________________________________________________________
социаль ипотека буенча исәпкә алу нормасыннан түбәнрәк,
________________________________________________________________________
санитария һәм техник таләпләргә җавап бирми торган
________________________________________________________________________
торак урынында яшәү)
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
(торак хокуклары объектының төрен күрсәтегез: изоляцияләнгән (коммуналь),
________________________________________________________________________
бүлмәләр саны)
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
_________________________________________________________________бәйле рәвештә

Социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга минем гаиләмне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне үз эченә алган билгеләнгән форма буенча гаризага анкета беркетелә.

Мине ____ кешедән торган гаиләм белән социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алуыгызны сорыйм.

Мин һәм гаиләм әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерүгә, алар биргән, шулай ук махсуслаштырылган оешма (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт то-

рак фонды) тарафыннан бирелгән исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документларны тикшерүгә ризалык бирәбез.

Мине һәм гаиләм әгъзаларын, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән белешмәләр үзгәргән вакытта, бер ай эчендә алар турында җирле үзидарә органнарына исәпкә алу урыны буенча язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш булуыбыз турында кисәттеләр.

Мин һәм гаиләм әгъзалары гаризада күрсәтелмәгән белешмәләр ачыкланган очракта закон тәртибендә исәптән төшерелүебез белән килешәбез.

Керемнәрем турында, милек хокукында үземнеке булган мөлкәт турында мәгълүматларны тиешле салым органнарында һәм күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу буенча органнарда тикшерүгә ризалык бирәм.

Гариза бирүче________________________________________________________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, этисенең исеме, имзасы)

Эшкә сәләтле гаилә әгъзалары:1.__________________________________________

2.____________________________________________________________

3.____________________________________________________________

4.____________________________________________________________

5.____________________________________________________________

6.____________________________________________________________

(барлык эшкә сәләтле гаилә әгъзаларының имзалары)

«___________» ____________ 20__ ел.

(Дата язмача)

2 нче кушымта

# ГАРИЗА БИРҮЧЕ АНКЕТАСЫ

1. Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме ____________________
(тулысынча)

2. Адрес буенча яшим ______________________________ [ ][ ][ ][ ]
(район, урам, йорт, фатир, бүлмә) (24 бүлек коды)

______________________________________________________________

______________________________________________________________
(контактлы өй, эш телефонын күрсәтергә)

3. Шәхесне раслаучы документ _________________________________
(документ төре)

серия ______ номер _______________ кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән

______________________________________________________________

4. Туу датасы ______________________________ [ ][ ][ ][ ]
(число, ай, ел) (7 бүлек коды)

5. Туган урыны ______________________________ [ ][ ][ ][ ]
(шәһәр, район коды)

6. Салым түләүченең идентификацион номеры

[ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ]

(ИНН) (9 бүлек коды - барлык унике билгене күрсәтү)

7. Мәшгульлек: ______________________________________________ [ ]
(әгәр мөрәҗәгать итүче эшләми икән, эшсезлек сәбәбен күрсәтергә) (10 бүлек коды)

______________________________________________________________
(оешма, предприятие, бүлек, уку урыннарының тулы исемен күрсәтергә)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

9. Предприятие ИНН ___[ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ][ ]
(9 бүлек коды)

______________________________________________________________
(әгәр гариза бирүче эшләми икән, ИНН мәгънәсенә нульләр куела, ягъни.
Эшләмәүче өчен ИНН- 0 000 000 000)

10. Соңгы эш урынындагы стаж: ____________________ [ ][ ]
(еллар санын күрсәтергә)

11. Гомуми эш стажы ______________________________ [ ][ ]
(еллар санын күрсәтергә)

12. Мин һәм минем белән яшәүче гаилә әгъзалары милек хокукында торак мәйданны (өлешне) билибез: ________________________________
(нинди, кем, кайда, нигезләрне күрсәтергә)
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________ [ ]
(20 бүлек коды)

13. Наем шартнамәсе буенча ____________________________________________
________________________________________ (кем, конкрет күрсәтергә)

| № п/п | Мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Туганлык мөнәсәбәтләре | Прописка датасы | Аерым финанс-шәхси хисап булу | Мәйдан (гомуми / торак) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

14. Милек хокукында ______________________________________________

(кем, конкрет күрсәтергә)

| № п/п | Ф.И.О. (тулысынча) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Адрес | Торак хокуклары объекты (код) | Мәйдан (гомуми / торак) | Милек танылыгы буенча теркәлү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

15. Соңгы 5 елда мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары тарафыннан торак шартларын начарайтуга китергән торак урыннары белән гражданлык-хокукый алыш-бирешләр түбәндәге сәбәпләр буенча үткәрелде:

______________________________________________

(кайсы икәнен күрсәтергә)

16. Бер гаилә әгъзасы өчен гомуми мәйдан белән тәэмин итүнең гомуми дәрәҗәсе:

______________________________________________ ☐

(1 гаилә әгъзасына ничә кв. м. туры килә) (15 бүлек коды)

17. Фатир төре: ______________________________________________

(фатир төрен күрсәтергә: бүлмәләр саны)

______________________________________________ ☐

(төзекләндерү стандартын күрсәтергә) (23 бүлек коды)

______________________________________________

18. Теләсә нинди кертемгә банкларның һәм башка оешмаларның кредит акчаларын куллану (фатир, техника сатып алу, уку өчен түләү һ. б.) ☐
(Әйе 1, Юк 2)

19. Айлык түләүләр суммасы ______________________________________________

(конкрет түләү күләмен күрсәтергә)

20. Түләү вакытының ахыры________________________________________

21.Тутырылган декларация нигезендә гаиләдә 1 кешегә айлык җыелма керем

______________________________ ☐

(22 бүлек коды)

(салым инспекциясе тарафыннан расланган декларация формасы гражданнарны исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлегенә беркетелә)

22. Беренчел кертем кертү мөмкинлеге (пай тупланмалары) ________ ☐

(33 бүлек коды)

______________________________________________________________

(мөмкинлек булса, күпме икәнен күрсәтергә %: 10%, 20%, 30%, 30% тан артык

______________________________________________________________

23. Ташламалар категориясе: ______________________________ ☐

(бар / юк (астына сызарга) (36 бүлек коды)

______________________________________________________________

(ташламаларның нигезен, төрен күрсәтергә:

______________________________________________________________

авариячеләр, чернобыльчеләр, күп балалы, Бөек Ватан сугышында

катнашучылар, ______________________________________________

__________

сәламәтлек буенча, тузган торак, башкалар)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

24. Эш белән тәэмин итү өлкәсе буенча гражданнарның квоталар категориясе: ☐

(37 бүлек коды)

______________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең кайсы категориягә керүен күрсәтегез)

______________________________________________________________

25. Кирәкле торак төре
(теләгән): ______________________________________________ ☐

(35 бүлек коды)

______________________________________________________________

Әлеге гаризадагы мәгълүматлар түбәндәге датага дөрес һәм төгәл булуын раслыйм.

Гариза бирүче: ______________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме тулысынча, имзасы)

Яраклы
Эшкә сәләтле гаилә әгъзалары: 1.______________________________
2.______________________________________________
3.______________________________________________
4.______________________________________________
5.______________________________________________
6.______________________________________________

(барлык эшкә сәләтле гаилә әгъзаларының имзалары)

«__________» ____________ 20__ ел

(Дата язмача)

3 нче кушымта

# МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕНЕ ҺӘМ АНЫҢ ГАИЛӘСЕН СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА БУЕНЧА ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ӨЧЕН ИСӘПКӘ АЛУ МӘСЬӘЛӘСЕН КАРАУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Барлык гражданнар өчен уртак нигездә:

Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гражданның гаризасы;

финанс-шәхси счет күчермәсе;

өй китабыннан күчермә(-ләр);

торак шартларын тикшерү турында белешмә (тузган һәм авария хәлендәге торак өчен);

ордер (наем, поднаем, аренда, субаренда шартнамәсе);

аның җитәкчесе кул куйган һәм оешма мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу бурычы билгеләнгән очракларда), предприятие реквизитларын, гражданның эш урыны, аның вазыйфасы турындагы белешмәләрне үз эченә алган барлык эшләүче гаилә әгъзаларының эш урыннарыннан белешмә(-ләр);

барлык гаилә әгъзаларының керемнәрен раслаучы документлар:

узган ел өчен хезмәт хакы турында белешмә (2-НДФЛ формасы буенча);

салым инспекциясе билгесе белән узган календарь елы һәм агымдагы календарь елның узган хисап чоры өчен декларация (эшкуар өчен) яки йөкләнгән керем түләүгә күчкән эшкуарлар өчен йөкләнгән керемгә салым түләү таныклыгы (соңгы 6 ай өчен);

студент билеты яки уку урынын раслаучы документ (укучылар өчен);

стипендия алу турында белешмә (студентлар өчен);

пособие алу турында белешмә;

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан субсидияләр булганда субсидияләүне гарантияли торган документлар;

милектә торак булу яки аны читләштерү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыру турында белешмә (соңгы 5 елда мөрәҗәгать итүченең торак урынында яшәү урыны буенча, шул исәптән Россиянең башка төбәкләреннән дә теркәлгән барлык затларга);

торак бинага һәм җиргә хокукны билгели торган документлар күчермәләре (торак бинага һәм җиргә милек турындагы таныклыклар, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе һ. б.);

техник инвентаризация бюросы тарафыннан бирелгән торак урыны (фатир) техник паспорты, янәшәдәге (чиктәш-изоляцияләнгән) бүлмәләрдә яшәүчеләр исемлеге;

үткәрелгән дәүләт теркәве хокукларын раслаучы күчемсез милеккә хокук һәм аның белән алыш-биреш буенча бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

әлеге мәйданда барлык яшәүчеләр өчен – паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), ә гаиләнең балигъ булмаган

әгъзалары өчен - туу турында таныклыклар;

армиягә чакыру яшендәге ир-атлар өчен хәрби билет күчермәсе;

хезмәт стажын раслаучы хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (кадрлар бүлеге начальнигы раслаган барлык битләр);

туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар: никах турында таныклык (аерылышу), бала туу турындагы таныклык, никах контракты булу.

2. Яшәү өчен яраксыз торакта яшәүче гражданнар өчен: 1 нче пунктта күрсәтелгән документлар;

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының торак урыны яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы карары.

3. Ташламалары булган гражданнар өчен:

1 нче пунктта санап үтелгән документлар;

тиешле ташламаны раслаучы дәүләт циркуляры;

тиешле ташламаны раслаучы документлар: белешмәләр, таныклыклар;

әлеге хокукны исәпкә алып, чиратка баскан затлар өчен өстәмә мәйданга хокук турында документ.

Искәрмә. Кирәк булса, махсуслаштырылган оешма (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды) мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары турында өстәмә белешмәләр белән документлар соратып алырга хокуклы.

4 нче кушымта

РАСЛЫЙМ:

)

Түбән Кама шәһәре _________

(район, шәһәр исеме)

башкарма комитеты җитәкчесе

(җирле үзидарә органнары)

___________________________

(имза, дата)

200__ елның________________нан(нән)

МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕНЕҢ ГАИЛӘСЕН СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА БУЕНЧА ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ӨЧЕН ИСӘПКӘ КУЮ ТУРЫНДА _______НОМЕРЛЫ КҮРСӘТМӘ

Гариза бирүче ________________________________________________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

_______кешедән торган гаиләсе белән социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен яшәү урыны буенча/эш урыны буенча (астына сызарга) исәпкә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итте

______________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең гариза буенча мөрәҗәгать итү датасын күрсәтергә)

Гариза бирүче ________________________________________________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

гаилә белән түбәндәге адрес буенча теркәлгән:

____________________________________________________________________

(тулы адресны күрсәтергә)

______________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(торак йортта, фатирда, бүлмәдә)

______________________________________________________________________

гомуми мәйданы ________ кв. м, торак мәйданы ________ кв. м

Гариза бирүче

______________________________________________________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

________________________________________________________________ булып

(милекче, яллаучы, арендатор)

______________________________________________________________ нигезендә

(төрен һәм шартнамә реквизитларын яки милек документын күрсәтегез)

______________________________________________________________________тора.

Гариза бирүченең икенче мәйданы милектә яки файдалану

да: ____________________________________________________________________

____________________________________________________________

(адресын, төрен һәм шартнамә реквизитларын яки милек хокукы документын күрсәтергә)

______________________________________________________________________

___________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең һәр гаилә әгъзасына гомуми мәйданның ____ кв. м туры килә:

______________________________________________________________________

Гариза бирүче _____________________________________________________

(эш урынын тулысынча күрсәтергә)

__________________________________________________ вазыйфасында эшли

(гариза бирүче вазыйфасын күрсәтергә)

Аена 1 гаилә әгъзасы өчен гомуми керем ________________________________

(сумнарда күрсәтергә)

Гариза бирүче _________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме; гаиләдә торак ташламасына ия булган

______________________________________________________________________

берничә граждан булганда, нигез һәм ташламалар төрен күрсәтеп,

______________________________________________________________________

ташламалары булган барлык гаилә әгъзалары күрсәтелә)

______________________________________________________________________

торак ташламасы бар: ______________________________________________

______________________________________________________________________

___________________________________________________________ нигезендә

(норматив хокукый актка, медицина учреждениесе белешмәсенә,

______________________________________________________________________

башка документка сылтама)

Торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия:

______________________________________________________________________

(комиссия утырышы барган оешманың исеме)

______________________________________________________________________

гариза бирүчене _______________________________________________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

______________________________________________________________________

________ ккешедән торган гаиләсе белән социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алырга тәкъдим итә.

Кирәкле торак төре ____________________________________________________

Гаилә составын исәпкә алып, торак бинаның гомуми мәйданы нормативы

______________________________________________________________________

(гаилә әгъзалары санын һәм гаилә составын исәпкә алып гомуми мәйданны күрсәтергә)

Мөрәҗәгать итүченең гаиләсен исәпкә кую датасы ___________________________

(махсус оешманың җыелма исемлегенә кабул итү (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды), хатлар датасы һәм номеры)

______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы___________________________ районы җирле үзидарә ор

(район, шәһәр исеме)

ганы җитәкчесе боерыгы нигезендә

_____________ № ____ гариза бирүчегә:

____________________

(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

_______________________________________ _____кешедән торган гаиләгә

исәп номеры билгеләнә: _____________________________________________

(исап номерын күрсәтергә)

Иҗтимагый торак комиссиясе рәисе урынбасары: __________________

Иҗтимагый торак комиссиясе әгъзалары:

1. ___________________________________________________________________________

(фамилиясен, исемен, әтисенең исемен тулысынча күрсәтергә, имза, дата)

2 ____________________________________________________________________________

3. ___________________________________________________________________________

4. ___________________________________________________________________________

5 нче кушымта

РАСЛЫЙМ:
Түбән Кама шәһәре
(район, шәһәр исеме)
башкарма комитеты җитәкчесе
(җирле үзидарә органнары)
_______________________________
(имза, дата)

200__ елның________________нан(нән)

МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕНЕҢ ГАИЛӘСЕН СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА БУЕНЧА ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ӨЧЕН ИСӘПКӘ КУЮДАН БАШ ТАРТУ ТУРЫНДА _______ номерлы КҮРСӘТМӘ

Гариза бирүче _______________________________________________________________
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
_____ кешедән торган гаиләсе белән социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен яшәү/эш урыны буенча (астына сызарга) исәпкә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итте _______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең гариза буенча мөрәҗәгать итү датасын күрсәтергә)
Гариза бирүче ________________________________________________________
(эш урынын тулысынча күрсәтергә)
______________________________________________________вазыйфасында эшли
(гариза бирүче вазыйфасын күрсәтергә)
Мөрәҗәгать итүче гаиләсе белән түбәндәге адрес буенча теркәлгән: _______________
(тулы адресны күрсәтергә)
___________________________________________________________________________
(торак йортта, фатирда, бүлмәдә)
___________________________________________________________________________

_____ _________ гомуми мәйданы ________ кв. м, торак мәйданы ________ кв. м

Гариза бирүче _______________________________________________________________
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
__________________________________________________________булып тора
(милекче, яллаучы, арендатор)
______________________________________________________________нигезендә
(төрен һәм шартнамә реквизитларын яки милек документын күрсәтергә)
___________________________________________________________________________
Гаризс бирүченең икенче мәйданы милектә яки файдалану хокукында:
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(адресын, төрен һәм шартнамә реквизитларын
___________________________________________________________________________
яки милек документын күрсәтергә)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең һәр гаилә әгъзасына гомуми мәйданның _____кв. м туры килә.
Аена 1 гаилә әгъзасы өчен гомуми керем ____________________________________________
(сумнарда күрсәтергә)

Гариза бирүче ___________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме; гаиләдә торак ташламасына ия булган

___________________________________________________________________________
берничә граждан булганда, нигез һәм ташламалар төрен күрсәтеп,

___________________________________________________________________________
ташламалары булган барлык гаилә әгъзалары күчерелә)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

торак ташламасы бар: _____________________________________________________

___________________________________________________________________________

_______________________________________________________________ нигезендә
(норматив хокукый актка, медицина учреждениесе белешмәсенә,

___________________________________________________________________________
башка документка сылтама)

Торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия: ______________________________

___________________________________________________________________________
(комиссия утырган оешманың исеме)

___________________________________________________________________________

мөрәҗәгать итүчене һәм аның гаиләсен социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә куюдан баш
та: ____________________________________________________________
__
(сәбәбен күрсәтергә)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Гариза бирүчене _________________________________________________________
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

______ кешедән торган гаилә әгъзаларын да исәпкә куюдан баш тарта.

Иҗтимагый торак комиссиясе рәисе урынбасары: ______________________________

Иҗтимагый торак комиссиясе әгъзалары:

1. ________________________________________________________________________
(тулысынча фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, имзаны, датаны күрсәтергә)


2. ________________________________________________________________________

3. ________________________________________________________________________

4. ________________________________________________________________________

6 нчы кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 47-43-73 | Ispolkomgoroda.Nk@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе | 42-50-47 | Ilnar.Badretdinov@tatar.ru |
| Бүлек белгечләре | 42-50-48 | ZhilOtdel.nk@tatar.ru |